ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ ВЕТЕРИНАРИИ КАБИНЕТА МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.07.2016 г. Казань № 257-п

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 2013 елның 27 маендагы № 165-п боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазифасын үтәүгә карата административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

2015 елның 3 ноябрендәге “Дәүләт контрольлеген (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольлекне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында” № 306-ФЗ Федераль закон кабул ителү сәбәпле һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең норматив-хокукый актларын федераль законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 2013 елның 27 маендагы № 165-п боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазифасын үтәүгә карата административ регламентына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 19.01.2015 № 6-п, 15.12.2015 № 534-п боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктны түбәндәге эчтәлегендә бәян итәргә:

“1.2. Дәүләт вазифасын үтәүче булып Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе (алга таба – ТР МК БВИ) тора.

Дәүләт вазифасын турыдан-туры үтәүчеләр булып ТР МК БВИ территориаль бүлекләре (алга таба – ТР МК БВИ ТБ) тора.

Тиешле мәгълүматларны бердәм тикшерүләр реестрына кертү 2008 елның 26 декабрендәге “Дәүләт контрольлеген (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольлекне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау

турында” № 294-ФЗ Федераль законның 13.3 статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елныц 28 апрелендәге “Бердәм тикшерүләр реестрын төзү һәм алып бару кагыйдәләре турында” № 415 карары нигезендә ТР МК БВИнең вәкаләтле вазифаи заты тарафыннан башкарыла.

Дәүләт вазифасын үтәү ТР МК БВИ тарафыннан Татарстан Республикасы буенча Россельхознадзор идарәсе (тикшерүләрнең кабатлануларына юл куймау мәсьәләләре буенча) һәм прокуратура органнары (планнан тыш урынга чыгып тикшерүләр үткәрүне килештерү, планлы тикшерүләр үткәрүне килештерү мәсьәләләре буенча) белән үзара хезмәттәшлек итеп гамәлгә ашырыла.”;

1.3 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле яңа унҗиденче кызыл юлны өстәргә:

“Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 28 апрелендәге “Бердәм тикшерүләр реестрын төзү һәм алып бару кагыйдәләре турында” № 415 карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең № 415 карары) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 11.05.2015, № 19, 2825 ст.);”

Унҗиденче-егерме тугызынчы кызыл юлларны унсигезенче-утызынчы кызыл юллар итеп санарга;

1.6.1 пунктта түбәндәге эчтәлекле 5 пунктчаны өстәргә:

“5) тикшерүләрне оештырганда һәм үткәргәндә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән чорларда һәм тәртиптә, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән исемлеккә кертелгән документларны һәм (яки) мәгълүматларны, шул исәптән электрон рәвештә, башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә әлеге документлар һәм (яки) мәгълүматлар алар карамагында булган, дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалардан түләүсез нигездә соратырга һәм алырга.”;

1.6.2 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле 7.1 пунктчаны өстәргә:

“7.1) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән юридик затның җитәкчесен, башка вазифаи затын яки вәкаләтле вәкилен, шәхси эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен таныштырырга;”;

13 пунктчаны түбәндәге эчтәлегендә бәян итәргә:

“13) үткәрелгән тикшерү турында исәпкә алу дәфтәрендә язу теркәргә, андый дәфтәр юридик затта, шәхси эшмәкәрдә булган очракта;”;

түбәндәге эчтәлекле 14 пунктчаны өстәргә:

“14) юридик затның җитәкчесенә, башка вазифаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә № 294-ФЗ Федераль законның 26.1 статьясындагы нигезләмәләрнең эчтәлеген аңлатырга бурычлы.”;

1.7.1 пунктта түбәндәге эчтәлекле 2.1 һәм 2.2 пунктчаларын өстәргә:

“2.1) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында ТР МК БВИ ТБ тарафыннан бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынган, шушы документлар һәм (яки) мәгълүматлар алар карамагында булган оешмалардан алынган документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән танышырга;

2.2) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында сорала торган документларны һәм (яки) мәгълүматларны дәүләт контрольлеге (күзәтчелеге) органына, муниципаль контрольлек органына үз ихтыяры белән тапшырырга;”;

1.8 пунктны түбәндәге эчтәлегендә бәян итәргә:

“1.8. Дәүләт вазифасы үтәлешенең нәтиҗәләрен тасвирлау.

Тикшерүне үткәргән ТР МК БВИ ТБ вазифаи затлары тарафыннан тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге документлар төзелә:

ике нөсхәдә билгеләнгән рәвештәге акт. Актның үрнәк рәвеше Россия Икътисади үсеш министрлыгының № 141 боерыгы белән расланган;

№ 294-ФЗ Федераль законның 13.3 статьясы һәм РФ Хөкүмәтенең № 415 карары нигезендә бердәм тикшерүләр реестрына кертелгән тиешле мәгълүмат;

шушы Регламентның 1 кушымтасындагы үрнәк буенча (хокук бозу очрагы ачыкланган очракта) мәҗбүри таләпләрне бозу буенча ачыкланган очракларны юкка чыгару турында күрсәтмә;

РФ КоАП 10.6, 10.7, 10.8, 19.5 статьясының 8 һәм 8.1 өлешләрендә каралган административ хокук бозу билгеләре ачыкланганда, – административ хокук бозу турында беркетмә;

административ хокук бозу эше буенча карар;

РФ КоАП 14.43-14.46, 19.4 статьясының 1 өлешендә, 19.5 статьясының 15 өлешендә, 19.6, 19.7, 19.33 статьяларында каралган административ хокук бозу билгеләре ачыкланганда, – административ хокук бозу турында беркетмә.

ветеринария кагыйдәләрен бозуның саксызлык буенча РФ ҖК 249 статьясының 1 өлешендә каралган эпизоотияләрне яки бүтән төрле катлаулы нәтиҗәләрне таратуга китереп чыгарган очраклары өлешендә ветеринария законнарын бозу билгеләре ачыкланганда, – ТР МК БВИнең тикшерүне үткәрүче вазифаи затлары тарафыннан прокурор исеменә гариза төзелә һәм тикшерү акты тапшырыла.

Контрольлек буенча чара барышында контрольлек буенча чара үткәрү объекты булган хуҗалык эшчәнлегенең яки бүтән эшчәнлекнең законнардагы таләпләрне бозуга бәйле булуы ачыкланган очракта, аларны ачыклау, туктату һәм юкка чыгару мәсьәләләре ТР МК БВИ вәкаләтенә карамаса, ТР МК БВИ мондый хокук бозулар турындагы мәгълүматларны (белешмәләрне) Россия Федерациясенең

яки Татарстан Республикасының тиешле вәкаләтле дәүләт хакимияте органнарына җибәрергә бурычлы.

Гражданнардан, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрдән, юридик затлардан ТР МК БВИ кергән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан (алга таба – мөрәҗәгать итүче) алынган мәгълүматлар дәүләт вазифасын үтәү өчен нигез булган очракта, дәүләт вазифасын үтәү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчегә № 59-ФЗ Федераль законда билгеләнгән тәртиптә җавап җибәрелә.”;

2.2 пунктта түбәндәге эчтәлекле 2.2.3 пунктчасын өстәргә:

“2.2.3. Шушы Регламентның 2.2.1 пунктының 2 кызыл юлында күрсәтелгән тикшерүне үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документларны һәм (яки) мәгълүматларны алу зарурлыгы килеп туган очракта, тикшерүне үткәрү ТР МК БВИ башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле чорга, ләкин ун эш көненнән артмаган вакытка туктатылырга мөмкин. Тикшерүне үткәрүне кабат туктату рөхсәт ителми.

Тикшерү үткәрүне туктатып тору вакыты гамәлдә булган чорда территориядә, биналарда, төзелмәләрдә, корылмаларда, бүлмәләрдә, кече эшмәкәрлек субъектының бүтән объектларында ТР МК БВИнең аталган тикшерүгә бәйле булган гамәлләре дә туктатып торыла.”;

2.3.1 пунктчада түбәндәге эчтәлекле кызыл юлны өстәргә:

“2016 елның 1 гыйнварыннан башлап 2018 елның 31 декабренә кадәр булган чорда 2007 елның 24 июлендәге “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында” № 209-ФЗ Федераль законның 4 статьясындагы нигезләмәләр нигезендә кече эшмәкәрлек субъектларына кертелгән оешмаларга карата планлы тикшерүләр № 294-ФЗ Федераль законның 26.1 статьясындагы таләпләргә туры китереп оештырыла һәм үткәрелә.”;

2.3.2 пунктчада түбәндәге эчтәлекле кызыл юлны өстәргә:

“Планнан тыш тикшерүне үткәрү өчен юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозу буенча ачыкланган җитешсезлекләрне юкка чыгару турында күрсәтмәнең үтәлү чорының бетүе нигез булып торганда, мондый тикшерүнең предметы буларак бары тик ТР МК БВИ тарафыннан бирелгән күрсәтмәнең үтәлеше генә тора ала.”;

5 бүлектә:

үндүртенче кызыл юлда “Россия Федерациясе законнарында каралмаган” сүзләрен “Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда рөхсәт ителә” сүзләренә алмаштырырга.”;

5.1.8 пунктта түбәндәге эчтәлекле кызыл юлларны өстәргә:

“Зарурлык булганда, җаваплы башкаручы шушы Регламентның 1.6.1 пунктындагы 5 пунктчасындагы таләпләргә туры китереп билгеләнгән тәртиптә документларны һәм (яки) мәгълүматларны, шул исәптән электрон рәвештә сората һәм ала.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында салым серен яки закон белән саклана торган бүтән серне үз эченә алучы белешмәләре булган документларны һәм (яки) мәгълүматларны сорату бары тик тиешле белешмәләрне тикшерүнең юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлүен билгеләү зарурлыгы белән билгеләнгән очракта һәм аталган белешмәләрне бирүнең федераль законда каралган булуы шарты белән генә рөхсәт ителә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документларны һәм (яки) мәгълүматларны тапшыру, аларны ачу, шул исәптән № 294-ФЗ Федераль законда каралган очракларда алар белән таныштыру Россия Федерациясенең дәүләт сере яки закон белән саклана торган бүтән сер турындагы законнары таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.”;

5.2.6 пунктта:

унҗиденче кызыл юлда “тикшерүне үткәрә башлаганнан бирле егерме көннән артык түгел” сүзләрен “шушы Регламентның 2.2.1 пунктындагы таләпләренә туры китереп” сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле кызыл юлларны өстәргә:

“Зарурлык килеп туганда, җаваплы башкаручы шушы Регламентның 1.6.1 пунктынын 5 пунктчасындагы таләпләргә туры китереп билгеләнгән тәртиптә документларны һәм (яки) мәгълүматларны, шул исәптән электрон рәвештә сората һәм ала.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында салым серен яки закон белән саклана торган бүтән серне үз эченә алучы белешмәләре булган документларны һәм (яки) мәгълүматларны сорату бары тик тиешле белешмәләрне тикшерүнең юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлүен билгеләү зарурлыгы белән билгеләнгән очракта һәм аталган белешмәләрне бирүнең федераль законда каралган булуы шарты белән генә рөхсәт ителә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документларны һәм (яки) мәгълүматларны тапшыру, аларны ачу, шул исәптән № 294-ФЗ Федераль законда каралган очракларда алар белән таныштыру Россия Федерациясенең дәүләт сере яки закон белән саклана торган бүтән сер турындагы законнары таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.”;

5.2 пунктта түбәндәге эчтәлекле 5.2.10 пунктчасын өстәргә:

“5.2.10. Җаваплы башкаручы үткәрелгән тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу дәфтәрендә язу терки, бу дәфтәрне юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр РФ Икътисади үсеш министрлыгының № 414 боерыгы белән билгеләнгән үрнәк

рәвешендә алып барырга хокуклы. Үткәрелгән тикшерү турындагы язуда дәүләт контрольлеге (күзәтчелеге) органының аталышы, тикшерүне үткәрә башлау һәм тәмамлау даталары, аны үткәрү вакыты, хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм тикшерү предметы, ачыкланган хокук бозу очраклары һәм бирелгән күрсәтмәләр турында белешмәләр булырга тиеш, шулай ук тикшерүне үткәрүче вазифаи затның яки вазифаи затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазифасы, аның яки аларның имзалары күрсәтелә.

Тикшерүләрне исәпкә алу дәфтәре тегелгән булырга, номерланырга һәм юридик затның, шәхси эшмәкәрнең мөһере белән (мөһер булган очракта) таныкланырга тиеш. Тикшерүләрне исәпкә алу дәфтәре булмаган очракта тикшерү актында тиешле язу теркәлә.”;

5.4.8 пунктының беренче кызыл юлын түбәндәге эчтәлегендә бәян итәргә:

“5.4.8. Юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата тикшерү үткәрү җаваплы башкаручы тарафыннан шушы Регламентның 5.2.6 пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла. Тикшерү актын төзү шушы Регламентның 5.2.7 пунктына туры китереп гамәлгә ашырыла.”;

5.4 пунктны түбәндәге эчтәлекле 5.4.11 пунктчасы белән тулыландырырга:

“5.4.11. Җаваплы башкаручы үткәрелгән тикшерү турында язуны тикшерүләрне исәпкә алу дәфтәрендә шушы Регламентның 5.2.10 пунктындагы таләпләренә туры китереп терки.”.

2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары А.Н. Гыйбадуллинны җаваплы итеп билгеләргә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты
Баш ветеринария идарәсе башлыгы –
Татарстан Республикасының Баш дәүләт
ветеринария инспекторы А.Г. Хисаметдинов